ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.08.2022 п.г.т.Алексеевское № 297

**Муниципаль оешма җитәкчесе вазыйфасында эшкә керүче зат, шулай ук муниципаль оешма җитәкчесе тарафыннан керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең)балигъ булмаган балаларының керемнәре,мөлкәте һәм мөлкәти характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турындагы Нигезләмәне раслау хакында**

2012 елның 29 декабрендәге 280-ФЗ номерлы «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре җитәкчеләре хезмәтенә түләүнең ачык механизмын булдыру һәм әлеге учреждение җитәкчеләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» гы Федераль законы, Россия Федерациясе Хезмәт Кодексының 275 статьясындагы дүртенче өлеше, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керә торган затның һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе җитәкчесенең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирүе хакында» 2013 елның 28 февралендәге 137 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән,

**карар бирәм:**

1. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү хакындагы Нигезләмәне (кушымта) расларга.

2. Үз көчен югалткан дип таныйрга:

- Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 22 маенда кабул ителгән 211 номерлы «Муниципаль учреждение җитәкчесе

вазыйфасына эшкә керүче зат, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында Нигезләмәне раслау хакында»гы карары;

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 22 маендагы 211 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 22 маендагы 173 номерлы «Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» гы карары.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О. А. Гайнуллин**

Алексеевск муниципаль
районы Башкарма комитетының
01.08.2022 ел № 297 карарына
кушымта

**Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү хакындагы Нигезләмә**

1. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче зат, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе эш бирүчегә үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат (алга таба - керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат) язма һәм электрон рәвештә тапшырырга тиеш.

2. Керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат муниципаль район башкарма органына Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган белешмә формасында, ел саен, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү өчен билгеләнгән срокларда муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан тапшырыла.

3. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә килүче зат тәкъдим итә:

а) муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керешү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен барлык чыганаклардан алынган керемнәре (элеккеге эш урынындагы яисә сайланулы вазыйфаны биләү урынындагы керемнәрне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында мәгълүмат, шулай ук шулай ук милек хокукындагы мөлкәт турында мәгълүмат һәм җитәкче вазыйфасына керү өчен документлар тапшыру аена кадәрге айның беренче числосына (хисап датасына) мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында;

б) хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан алынган керемнәре (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында җитәкче вазыйфасына керешү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен мәгълүмат, шулай ук җитәкче вазыйфасына керешүгә кадәрге айның беренче числосына (хисап датасына) милек хокукында булган мөлкәте турында һәм аларның мөлкәти характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүмат.

4. Муниципаль учреждение җитәкчесе ел саен тәкъдим итә:

а) хисап чорында(1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне һәм башка түләүләрне кертеп) алынган керемнәр турында мәгълүмат, шулай ук хисап чоры азагына мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат;

б) хисап чорына (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр)хатынының(иренең), балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан(хезмәт хакын, пенсияләр, пособиеләр һәм башка түләүләр кертеп) керемнәре турында мәгълүмат, шулай ук хисап чорының азагына аларның мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат;

в) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешен, пайларын), цифрлы финанс активлары, санлы валюта сатып алуга кагылышлы алыш-биреш буенча, хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр, үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүмат, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганга кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары хакында мәгълүмат.

5. Муниципаль учреждение җитәкчесе үзләренә тапшырылган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турындагы мәгълүматта нинди дә булса мәгълүматлар чагылдырылмавын яки тулысынча чагылдырылмавын ачыклаган очракта, ул төгәлләштерелгән мәгълүматларны мәгълүмат тапшырган көннән бер ай эчендә тапшырырга хокуклы.

Мондый төгәлләштерелгән белешмәләр срокны бозып бирелгән булып саналмый.

6. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче зат, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан тапшырылган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турындагы мәгълүматның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү учреждениенең вәкаләтле заты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

7. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә килүче зат, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан тапшырыла торган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турындагы мәгълүмат, әгәр федераль закон белән алар дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларга кертелмәгән булса,әлеге Нигезләмә нигезендә конфиденциаль характердагы белешмәләр булып тора.

8. Вазыйфаи бурычларына керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат белән эш итү булган вазыйфаи затлар, аларны халыкка чыгаруга яисә Россия Федерациясе законнарында каралмаган максатларда файдалануда гаепле гамәлгә куючының вазыйфаи затлары Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

9. Әлеге Нигезләмә нигезендә тапшырылган керемнәр, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат һәм әлеге урында мәгълүматның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат муниципаль учреждение җитәкчесенең Шәхси Эшенә кушыла.

10. Әлеге Нигезләмә нигезендә керемнәр, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшырган зат муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына билгеләнмәгән булса, күрсәтелгән мәгълүмат аның язма гаризасы буенча башка документлар белән бергә кире кайтарыла, ә язма гариза булмаганда юкка чыгарылырга тиеш.

11. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына кергәндә затның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирмәве яки белә торып ялган яки тулы булмаган мәгълүмат бирүе күрсәтелгән затны муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

12. Муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшырмау яки тулы булмаган яки дөрес булмаган мәгълүматларны тапшыру, эш бирүче ягыннан аңа ышаныч югалу сәбәпле, аның белән төзелгән хезмәт килешүен өзү өчен нигез булып тора (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 81 ст.1 өлешенең 7.1 пункты).

**Башкарма комитетның**
**Эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**